

# Мифтахетдинов Минеахмат-
# участник первой мировой войны

Мифтахетдинов Минәхмәт 1890 елда Алабуга өязенең Салагыш волостендагы Бәзәкә авылында Мифтахетдин Хисаметдинов һәм Фатыйха Мехәмәтвәлиева гаиләсендә туа. Бөтенроссия переписе узган 1897 елда аларның гаиләсендә тагын энесе Минһаҗетдин (1895 елгы) һәм әбисе Гафифә Бигиева (1827елгы) була (А.Х.Мәхмүтова. "Колыбель моя, Бизяки",стр.455, п.188).

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан, әле яңа гына өйләнгән Минәхмәт абзыйны солдат хезмәтенә алып, Ревель (бүген Таллинн) шәһәрендә урнашкан 89-нчы Беломорск пехота полкына җибәрәләр. Ул шунда сугыш башланганны каршылый.

Карпат таулары тирәсендә барган сугышларда 1915 елның 28 мартында авыр яраланып ("ранение в левую лопатку и сторону груди"), аны башта 23-нче пехота дивизиясенең "перевязочный отрядына" җибәрәләр. Авыр яраларын чистартып бәйләгәч, Минәхмәт абзыйны тылга Мәскәүдәге госпитальгә озаталар. 1915 елның 11 маенда Мәскәүдән Казандагы №9 шәһәр госпиталенә күчерәләр.

Минәхмәт абзый артыннан сугышка энесе Минһаҗетдин да китә. 1916 елның 24 ноябрендә Украинаның бүгенге Ивано-Франковск өлкәсендәге Галич шәһәре янында ул бик авыр җәрәхәтләр ала: уң күзе, ике кулы һәм аяклары яралана. Госпитальдә чагында аны **4 дәрәҗәле Георгий кресты** белән бүләклиләр. Минһаҗетдин абзый мондый югары бүләккә лаек булган **бердәнбер бәзәкәле** бүгенге көндә һәм бу сугышта сугышчан бүләк алган өченче авылдашыбыз. Аның турында озакламый сезнең игътибарга аерым язма әзерләрбез.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Низамутдин Сайф-мул-отч | 45 | г/кр | | Малм/у. Вят/губ | портной |
| | Факиха Шар – сес | 19 | баш | | | |
| | Дети Низ-дина: | | | | | |
| | Минирахман Низам | 17 | г/кр | | | 3 5 |
| | Габдрахман Низ | 9 | г/кр | | | |
| | Бибикамал Низ | 13 | г/кр | | | |
| | Бибигадия Низ | 3 | г/кр | | | |
| | Гульниса Исхакова | 17 | баш | | | |
| 184 | М-карим М-шарипов | 70 | башк | | | |
| | Минигул М-кар. | 17 | | | | вдов 4 2 |
| | Ахметьян Г-сатт – зять | 55 | | | | умалиш.с рожд. |
| | Фатиха Мух-кар | 40 | | | | |
| | Мухаметьян Ахм. | 16 | | | | |
| | Фатхия Ахм. | 6м-ц | | | | |
| 185 | Хамидулла Файзуллин | 35 | башк | | | 2 3 |
| | Магуфура Гизатуллина | 34 | | | | |
| | Минизиган | 8 | | | | |
| | Гилмизиган | 4 | | | | |
| | Мутигулла | 1,5 | | | | |
| 186 | М-зариф Файзуллин | 30 | башк | | | 1 1 |
| | Муглифа Ильясова – м | 68 | | | | |
| 187 | Сайфул-н Г-халим Г-галл | 64 | тепт | | медресе | ук/мулла |
| | Бибидуррателзамал М-лат | 35 | тепт | | У муллы | |
| | Гайнутдин | 24 | тепт | | медресе | н/ч запаса |
| | Рабигитдин | 22 | тепт | | медресе | |
| | Бибигафифа Ахметьянова | 21 | тепт | | У муллы | |
| | Вазиха Рабиг | 2 | тепт | | | 6м 5ж |
| | Рафига Раб | 6 | тепт | | | |
| | Рафигитдин Г-халимов | 20 | тепт | | медресе | |
| | Ахметсафа Г-хал | 12 | тепт | | медресе | в Иж-Буби |
| | М-вафа Г-хал-в | 8 | тепт | | | |
| | Фахира Г-хал-ва | 3 | тепт | | | |
| 188 | Муфтахутдин Хисамут-в | 40 | башк | | | н/ч запаса |
| | Фатиха Мух-валиева | 35 | | | | 3 2 |
| | Миниахмет | 6 | | | | |
| | Мингазетдин | 1,5 | | | | |
| | Гафифа Бигиева | 70 | | | | |
| 189 | Арслангали Хисам-нов | 50 | башк | | | 3 2 |
| | Бибигазиза Нуриуллина | 28 | | | | |
| | Багаутдин | 12 | | | | |
| | Низамутдин | 1 | | | | |
| | Латифа | 17 | | | | |
| 190 | Набиулла Зайнитдинов | 37 | башк | | | 5 2 |
| | Шамсинагар Мух-гал | 24 | | | | |

# Муфтахатин Ахмет Христамутын.

*(Мифтахетдинов Минеахмат)*

Ранен/контужен. Именные списки потерь

Должность/Звание: рядовой

Воинская часть: 89-й пехотный Беломорский полк

Место рождения: Вятская губ., Евралуский уезд, Салаушская вол., с. Бадакиа

Причина выбытия: ранен/контужен

Место выбытия: Карпаты; перевязочный отряд 23 пехотной дивизии

Дата события: 15.03.1915 - 01.04.1915

Тип документа: Именные списки потерь

Архив: Российский Государственный Военно-исторический архив

Фонд: №16196, Особое делопроизводство по сбору и регистрации сведений о выбывших за смертью или за ранами, а также пропавших без вести воинских чинах, действующих против неприятельских армий (1914 - 1918)

Опись: №1, Именные списки потерь солдат и офицеров 1 мировой войны 1914-1918 гг. (по полкам и бригадам)

Дело: Именные списки потерь солдат 89 пехотного Беломорского полка

Документ: №1107, Список воинских чинов 89 пехотного Беломорского полка убитых, пропавших без вести и взятых в плен неприятелем, а также раненых и контуженных в боях на Карпатах, Автор: 89-й пехотный Беломорский полк, 1915-05-14

Форма № 57.

Начальнику 23 пѣхотной дивизіи.

16

59

СОСЧИТАНО

ОСОБОЕ ОТДѢЛЕНІЕ
24. МАЯ. 1915 – 131611
ГЛАВНАГО ШТАБА

ПЕРЕПИСАНО

# Списокъ №14


воинскихъ чиновъ 89 пѣх. Бѣломорскаго полка убитыхъ, пропавшихъ безъ вѣсти и взятыхъ въ плѣнъ непріятелемъ, а также раненныхъ и контуженныхъ въ бояхъ на Карпатахъ

Иоритъ

Шт. 23 п. дивизіи
„14. МАЙ 1915 г.
Вход. № 1107

„14" Мая 1915 года

№ 791.



**Муттахатдинов Мин-Ахмет** *(Мифтахетдинов Минеахмат)*

Ранен/контужен. Картотека потерь

Должность/Звание: рядовой

Воинская часть: 89-й пехотный Беломорский полк

Место рождения: Вятская губ., Елабужский уезд

Причина выбытия: ранен/контужен

Дата выбытия: 28.03.1915

Дата события: 11.05.1915


Тип документа: Уведомление о приеме раненого

Архив: Российский Государственный Военно-исторический архив

Фонд: Картотека бюро учета потерь в Первой мировой войне (офицеров и солдат)

Шкаф: без номера

Ящик: 2269-М



1265

Мутахадинов

54

Форма А.

Всероссійскій Союзъ Городовъ помощи больнымъ и раненымъ воинамъ.

УВѢДОМЛЕНІЕ о ПРІЕМѢ

раненаго или больного, поступившаго съ театра военныхъ дѣйствій.

Губернія

Уѣздъ

Городъ, селеніе Казань

Лѣчебница

Спец. госпиталь (лазаретъ, патронажъ) Приюдск № 9

№ 211

1. Фамилія Муттахаджиновъ Мин-Ахмед

Имя — отчество —

2. Хол., женат., вдовъ

3. Неграм., грамотн., образован. 4. Возрастъ 22

5. Народность тат

6. Вѣроисповѣданіе мусульм

7. Войсков. часть, должность (занятіе) рядовой 89 Беломорского полка

8. Мѣсто родины: губ. Вятская

уѣздъ (городъ) Елабужский

9. Мѣстожительство (передъ войной): губ. г. Ревель

уѣздъ (городъ) на действит. служ

10. Занятіе (передъ войной)

11. Болѣзнь или поврежденіе (какое, когда и гдѣ получено) ран в лев лопатку и сторону груди 28 марта гдѣ не помнит

12. Принятъ мѣс. мая числа 11 1915 г.

13. Откуда прибылъ изъ Москвы

Подпись врача

Түбәндә Минеәхмәт абзый хезмәт иткән полкның кыска тарихы белән таныштырабыз:

# Беломорский 89-й пехотный полк

**89-й пехотный Беломорский Его Императорского Высочества Наследника Цесаревича полк** — воинская часть Русской Императорской армии.

## Формирования и кампании полка

### Морские полки

Полк имеет старшинство с 29 апреля 1803 г., когда были сформированы на гренадерском положении морские полки, имевшие непосредственную связь с морскими командами времён Петра Великого, комплектовавшимися для портовой и корабельной службы и для пополнения убыли судовых экипажей.

В 1720 году из этих команд были составлены особые морские солдатские команды, разделённые на роты, причисленные к разным судам и нёсшие, кроме того, службу в Санкт-Петербургском и Кронштадтском адмиралтействах. 7 июня 1733 г. из этих команд были сформированы два трёхбатальонных морских полка. Полки эти, в 1734 году расписанные по судам эскадры, были посланы в помощь войскам Миниха, участвовали в осаде Данцига.

В 1757 году из морских полков были составлены: адмиралтейский батальон и корабельные и галерные команды; но такой порядок продержался лишь до 1764 года, когда было из этих частей было сформировано четыре морских батальона. В Семилетнюю войну морские батальоны участвовали в осаде Мемеля, были в составе десанта при взятии его 24 июня 1757 года и принимали участие в осаде Кольберга в 1760—1761 годах.

Затем морские батальоны были на судах эскадры адмирала Спиридова во время его экспедиции в Средиземное море в 1769—1770 годах и проявили особое мужество при штурме крепости Наварин 10 апреля 1770 года, будучи в составе десантных колонн под командой генерал-майора князя Долгорукова. Далее морские батальоны, находясь на судах эскадры, приняли участие в Чесменском сражении 24 июня 1770 года.

В 1777 году каждый из 4 морских батальонов был развёрнут в два отдельных батальона (общим числом 8), к которым в 1797 году был прибавлен ещё один.

29 апреля 1803 года из морских батальонов Балтийского флота были сформированы на гренадерском положении три морских трёхбатальонных полка. Шефом 1-го и вместе с тем имеющим право инспектирования других полков был назначен генерал-майор Ширков; в 3-м морском полку шефом был назначен генерал-майор Гинкуль, заменённый вскоре известным впоследствии героем Отечественной войны генералом Неверовским, командиром полка назначен был полковник Гамен, который также заметно отличился в войнах против Наполеона.

Морские полки в кампании 1805 г. участвовали в десантных операциях отряда графа Толстого, занявшего потом Ганновер. После Аустерлицкого сражения часть морских полков (по одному батальону от каждого полка) была расписана на суда эскадры адмирала Сенявина, оперировавшей в 1806 г. в Средиземном море, и принимали участие в морском бою при Афонской горе и в занятии островов Тенедоса и Лемноса. Этот сводный морской полк был назван 2-м морским полком, а остававшиеся в Кронштадте два батальона 2-го морского полка были приписаны по одному к 1-му и 3-му полкам.

После Отечественной войны 1812 года и Заграничных походов 1813 и 1814 гг., в которых 1 и 3-й морские полки также приняли участие, они были расквартированы в Царстве Польском и при усмирении польского восстания в 1831 г. участвовали с отличием в сражениях при Остроленке и Грохове, где особенно отличился 3-й морской полк под командованием полковника Сафонова. Во время штурма Варшавы морские полки были в составе 1-го корпуса, бравшего приступом укрепления Воли, где опять особенно отличился 3-й морской полк, получивший за штурм Варшавы Георгиевское знамя с надписью: «За взятие приступом Варшавы 25 и 26 августа 1831 г.».

## Невский пехотный полк

В 1833 году морские полки были расформированы, причём 1 и 3-й батальоны 1-го полка и 1-й батальон 3-го полка были присоединены к Невскому пехотному полку, став 3, 4 и 6-м батальонами этого полка, который тогда же был назван Невским морским полком.

В 1856 году Невский полк был переформирован в трёхбатальонный состав, а 4-й действующий батальон был назван 4-м резервным батальоном Невского полка.

## Беломорский полк



*Солдаты Беломорского полка на фронте Первой мировой.*

6 апреля 1863 г. из этого батальона и бессрочно-отпускных 5 и 6-го батальонов Невского пехотного полка был сформирован двухбатальонный Невский резервный пехотный полк, переименованный 13 августа того же года в Беломорский пехотный полк и развернутый 21 августа того же года в трёхбатальонный состав; 25 марта 1864 г. полк получил № 89. В 1865 г. Беломорскому полку было пожаловано Георгиевское знамя, с надписями под орлом: «1733—1833 гг.» и «За взятие приступом Варшавы 25 и 26 августа 1831 г.», при особом Высочайшем рескрипте, устанавливавшем связь 1-го батальона Беломорского полка с морскими полками, учрежденными императрицей Анной Иоанновной в 1733 году.

Во время русско-турецкой кампании 1877—1878 гг. Беломорский полк выделил из своего состава 7 офицеров и 45 нижних чинов на пополнение убыли в рядах Дунайской армии.

В 1879 году полк развёрнут в четырёхбатальонный состав.

В 1903 г., по случаю 100-летнего юбилея, Беломорскому полку было пожаловано новое знамя с добавлением к прежним надписям: «1803—1903» и с Александровской юбилейной лентой. Из других отличий полк имел гренадерский бой, присвоенный морским полкам, сформированным в 1803 г.

Высочайшим приказом от 30 июля 1915 года Беломорскому полку пожаловано шефство Наследника Цесаревича Алексея Николаевича и полк наименован «89-й пехотный Беломорский Его Императорского Высочества Наследника Цесаревича полк».

В 1917 году 89-й пехотный Беломорский полк входил в состав 1-й бригады 23-й пехотной дивизии Русской Императорской армии. В конце 1917 года 1-я бригада вошла в состав Ревельского укреплённого района Морской крепости Императора Петра Великого.

Полковой праздник — 9 мая.

Квартира – г. Ревель (Таллинн) Эстляндской губернии (1914 год)

Сугыштан соң Минәхмәт абзый авылга исән-имин булып кайта. 1917 елгы переписьтә аның гаиләсендә 3 кеше (1894 елгы хатыны, энесе) булуы күрсәтелгән (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя, Бизяки”, с.499, п.420).

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 419 | Набиуллин Салимулла-м.55, 6 б.24, 20,16,13,12,7, ж. 25,2д. 3,1, сн. 20 | 30 | 6 | 1 | 11 | 31 | 30 | 35 | | | 3 яч. |
| 420 | Мифтахетдинов Минахмет ж.23, б.23 | 26 | 3 | 1 | 11 | 4 | 15 | 18 | 1 | | |
| 421 | Шарафетдинов Фархетдин ж.50, с. 23 | 55 | 2 | 1 | 1 | 31 | 10 | 8 | 5 | | |
| 422 | Шарафетдинов Гимазетдин ж.44, с. 8, 2д. 15,9 | 44 | 1 | 1 | | 41 | 4 | 6,5 | | | |
| 423 | Шарафетдинов Хуснутдин-мел. торг ж.55, с. 26, 2д. 17,12 | 60 | 3 | 1 | 11 | 54 | 13 | 13 | | | |
| 424 | Шайхетдинов Шаяхмет ж.30, 2с. 6,2 | 35 | 2 | 1 | 1 | 21 | 10 | 13 | | | |
| 425 | Шарафетдинов Тазетдин ж.62, с. 21, в.1 | 68 | 4 | 21 | 11 | 5 | 20 | 24 | | 2 | |
| 426 | Низаметдинов Гимазетдин ж.50, 3с. 26,19,8, в.3, сн. 20 | 53 | 4 | 2 | 2 | 6 2 2к. | 20 | 24 | | 2 | |
| 427 | Ямалетдинов Ахмадша ж.45, с. 12, 2д. 8,6 | 50 | 1,5 | 1 | 11 | 2 | 7 | 9 | 1 | | |
| 428 | Ямалетдинов Мифтахет-дин-Б.з. ж.25, 2д. 6,4 | 40 | 1,5 | 1 | | | 7 | 10 | | | |
| 429 | Гизатуллин Миникай ж.40, 3с. 10,7,4 | 45 | 2 | | | | 10 | 15 | | | |
| 430 | Хурматуллин Адиятулла м.50, б.18 | 35 | 2 | | | | 10 | 13 | | | |
| 431 | Мухамадьянов Шакирьян м.60, ж.25 | 32 | 2 | 1 | 11 | 11 | 10 | 13 | | | |
| 432 | Юсупов Хуснутдин – посторонний ж.68, 5с. 23,21,20,7,4, 3д. 18,11,9 | 80 | - | | | | | | | | |
| 433 | Гибадуллин Габдрахман ж.36, 2с. 7,6, 2д. 5,3 | 40 | 2 | 1 | 11 | 4 | 10 | 13 | | | |
| 434 | Хабибуллин Хайрулла ж.60, 2с. 21,16 | 65 | 3 | 2 | 1 | 41 | 15 | 19 | | | |
| 435 | Сагындыков Камалетдин 2с. 33,23, сн. 20, внук 2 | 70 | 5 | 2 | 11 | 43 | 25 | 33 | | | |
| 436 | Галимов Нуретдин | 20 | 2 | | 11 | 21 | 10 | 13 | | | |
| 437 | Галлямов Гильмулла | 21 | 1 | 1 | | | 5 | 6,5 | | | |
| 438 | Сиразетдинов Низаметдин ж.40, 2с. 21,11, 3д. 18,8,1 | 45 | 2 | 2 | 22 | 42 | 10 | 13 | | | |
| 439 | Хисматуллин Гайнулла ж.45, 3с. 23,12,8, д. 4 | 60 | 5 | 1 | 1 | 32 | 25 | 45 | | | |



1925 елгы переписьта да Мөфтиев (шулай Мифтахетдиновны кыскарткannар) Минәхмәт абзый гаиләсендә 3 кеше булуы күрсәтелгән: бу вакытта инде аларның кызы Зәйтүнә (1918 елгы) була (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя, Бизяки”, стр.504, п.121).

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 75 | Шиябутдинов Авзалетдин | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 76 | Закиров Фатах | 5 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 77 | Шакиров Миниахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 78 | Гафаров Хузахмат | 6 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 79 | Гафаров Гарай | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 80 | Шабаев Муфтах | 8 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 81 | Давлятшин Гарай | 9 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 82 | Серазетдинов Гильфан | 6 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 83 | Ахмадянов Назиб | 9 | 1,71 | 1,8 | 3,51 |
| 84 | Шибаев Фарди | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 85 | Шибаев Аглей | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 86 | Тазетдинов Фатах | 5 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 87 | Хадеев Минахмат | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 88 | Ахмадянов Исхак | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 89 | Мухамедянов Хисами | 8 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 90 | Шайгалямов Фатах | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 91 | Хисматуллин Давлей | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 92 | Гайнутдинов Багаутдин | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 93 | Гайнутдинов Зайнутдин | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 94 | Сахабутдинов Возит | 3 | -76 | -80 | 1,56 |
| 95 | Хисамутдинов Насиб | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 96 | Гимазетдинов Авзалетдин | 6 | -95 | 1 | 1,95 |
| 97 | Мухамадянов Галиахмат | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 98 | Альмухаматов Миниахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 99 | Фазлеев Хузя | 4 | -57 | -60 | 1,17 |
| 100 | Хафизов Закир | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 101 | Закиров Ахун | 2 | -19 | -20 | -39 |
| 102 | Хубихузин Фардей | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 103 | Якопов Минихан | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 104 | Сагабутдинов Харамай | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 105 | Мухамедянов Хузя | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 106 | Альмачева Фазиля | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 107 | Насыров Хуснутдин | 10 | 1,9 | 2 | 3,9 |
| 108 | Шакиров Фархи | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 109 | Газизов Сахаб | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 110 | Гимазетдинов Гильфан | 7 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 111 | Шарафеев Галимян | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 112 | Хазеев Сахибулахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 113 | Якопов Фатхий | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 114 | Денеев Галиахмат | 2 | -38 | -40 | -78 |
| 115 | Денеев Миниахмат | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 116 | Набиуллин Галимулла | 6 | -95 | 1 | 1,95 |
| 117 | Гилфанутдинов Гимазетдин | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 118 | Шарипов Галли | 4 | -57 | -60 | 1,17 |
| 119 | Бикмухаметов Галиахмат | 8 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 120 | Набиуллин Гатаулла | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 121 | Муфтиев Миниахмат | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 122 | Гимазтинов Гауни | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 123 | Мусинов Закир | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 124 | Гайнутдинов Мухамат | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 125 | Арсланов Багаутдин | 3 | -76 | -80 | 1,56 |
| 126 | Арсланов Даулат | 4 | -95 | 1 | 1,95 |
| | | 2 | -57 | -57 | 1,17 |



1925 елгы переписьта Минәхмәт абзый тагын бер тапкыр язылган. Бәлки яшь гаилә башка чыгар өчен үзләренә яңа милектә өй сала башлаганнардыр һәм перепись өй башыннан баргач аларны тагын списокка керткәннәр. Бу юлы инде фамилиясен авылдагы


кушаматыннан алганнар: “Кабишов Минәхмәт” (А.Х.Мәхмүтова. “Колыбель моя,Бизяки”, стр.510, п.427).

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 387 | Гайнутдинов Миназетдин | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 388 | Гайнутдинов Хабибулла | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 389 | Мингазетдинов Шараф | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 390 | Насыров Башар | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 391 | Галямов Гариф | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 392 | Камалетдинов Фархутдин | 1 | -19 | -20 | -39 |
| 393 | Хамидуллин Гатиятулла | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 394 | Гайнуллин Закир | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 395 | Шарифуллин Серазетдин | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 396 | Мухтасипов Галей | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 397 | Мухтасипов Хикматулла | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 398 | Шакиров Давлятша | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 399 | Шакиров Закир | 2 | -57 | -60 | 1,17 |
| 400 | Сабитов Минахмет | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 401 | Сабитов Давлятша | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 402 | Музафаров Зариф | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 403 | Хузин Мулланур | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 404 | Богдагареев Загретдин | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 405 | Галимов Мухамадей | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 406 | Хубихузин Миназетдин | 7 | 1,33 | 1,4 | 2,73 |
| 407 | Минихузин Мухамадий | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 408 | Хузин Нури | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 409 | Ахмадянов Ситдик | 9 | 1,71 | 1,8 | 3,51 |
| 410 | Калимуллин Гайнулла | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 411 | Ибрагимов Муфтахутдин | 7 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 412 | Ильясов Хузя | 6 | -95 | 1 | 1,95 |
| 413 | Серазутдинов Фархутдин | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 414 | Серазетдинов Гайфутдин | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 415 | Латыпов Ахмадшакир | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 416 | Латыпов Ахмадзариф | 6 | -95 | 1 | 1,95 |
| 417 | Латыпов Ахмадзакир | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 418 | Махмутов Нурий | 10 | 1,9 | 2 | 3,9 |
| 419 | Арчилов Бикмухамад | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 420 | Шигабутдинов Ахматзакир | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 421 | Шигабутдинов Шакир | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 422 | Шигабутдинов Назмутдин | 1 | -38 | -40 | -78 |
| 423 | Ямалеев Гильфан | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 424 | Давлятшин Салим | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 425 | Ахмадянов Галиахмат | 8 | 1,52 | 1,6 | 3,12 |
| 426 | Шарипов Закир | 10 | 1,9 | 2 | 3,9 |
| 427 | Кабишев Минахмат | 2 | -38 | -40 | -78 |
| 428 | Нугуманов Махмут | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 429 | Нугуманов Габдрахман | 6 | 1,14 | 1,2 | 2,34 |
| 430 | Гилфанов Биктимер | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 431 | Гараев Султан | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 432 | Гараев Мухамадгарай | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 433 | Ахмадянов Ахкамутдин | 2 | -38 | -40 | -78 |
| 434 | Гараев Минахмат | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 435 | Кабиров Назмутдин | 4 | -76 | -80 | 1,56 |
| 436 | Мингазетдинов Багаутдин | 5 | -95 | 1 | 1,95 |
| 437 | Мингазетдинов Камалетдин | 3 | -57 | -60 | 1,17 |
| 438 | Бахтигараев Шакир | 5 | -95 | 1 | 1,95 |

Бөек Ватан сугышы башлангач, 1942 елның 21 декабрендә Мифтахетдинов Минәхмәтне Бондюг военкоматы переосвидетельствование үткәреп “Годный к нестроевой службе” дип резервка куеп, аңа справка бирә. Ул сугыш беткәнче фронтка да, трудоармиягә дә алынмый шулай резервта кала.

Минәхмәт абзый 1965 елда бакыйлыкка китеп Бәзәкә зыяратында күмелә.

Бу язманы әзерләгәндә авылдашларның нәсел җепләрен табарга булышкан Фәния апа Латыйповага (Кәримова) зур рәхмәтебезне җиткерәбез!


НКО—СССР
Бондюжский
Районный
Военный комиссариат
Татарской Автономной Советской Социалистической Республики
„21. декабря 1942 г.
№ 255
гор. ____

**Справка**

Настоящим подтверждается, что гражданин Мифтахутдинов Минахмет
(фамилия, имя и отчество)
Родившийся в 1890 г. в ТАССР области город ____ район Бондюж село д. Бизяки явился на переосвидетельствование по приказу НКО 1942 г. № 336 и „21" декабря 1942 г. Комиссией при Бондюжск. Райвоенкомате Татарской области (республики) признан годным к нестроевой службе по ст. 31 гр. I

м. п.
004487
Райвоенком

Түбәндә Минәхмәт абзый гаиләсе, нәселе турындагы кызы Гөлнәфис һәм балалары язган истәлекләр белән таныштырабыз:

“Туган-тумачаңны, нәсел-нәсәбеңне белү фарыз”- дигәннәр борынгылар. Боларны белмичә, туган җиреңнең, илеңнең, нәселеңнең үткәнен, халкыңның тарихын белеп булмый. Гаилә ядкаръләрен кадерләп саклау, үз нәселеңнең абруе турында кайгырту фарыз. Мин үз бабам белән горурланам. Мөфтиев Миннәхмәт Мөфтәхетдин улы 1890 елда Алабуга өязе Салагыш волостендагы Бәзәкә авылында, Мөфтәхетдин һәм

Фатихабану гаиләсендә дөньяга аваз сала. Бик яшьли ятим калып, дөньяның ачысын-төчесен кечкенәдән татырга туры килә. Яшь булуына карамастан, Гатаулла кызы Минеһәдия белән тормыш корып җибәрәләр, бабайга 17, ә әбигә нибары 16 яшь була. Гаилә бәхетен тоярга өлгерми калалар яшьләр, сугыш дигән афәт *(беренче бөтендөнья сугышы 1914-18 еллардагы)* яшьләрнең хыялларын җимерә. Миннәхмәт бабайны армияга алалар. Минеһәдия әби яшь килеш тормыш арбасына җигелә. Аңа тормышны алып барырга абыйсы Мөхәммәтдин ярдәм итә.

Сугыштан соң бабай исән-сау авылыбызга кайту бәхетенә ирешә. Сугышта авыр яраланып II группа инвалид булып кайта. Беренче бөтендөнья сугышыннан соңгы еллар... Авыр еллар, ачлык еллары. Колхоз оешкан елларны әби белән бабай урта хәлле крестьяннар санында булалар. Аларны чактан гына кулак итеп кумыйча калалар: сыерларын, атларын алып чыгып китәләр.

Аларның гаиләсендә 10 бала дөньяга аваз сала: беренче бала булып 1918 елның 14 сентябрендә -Зәйтунә, аннары Шафига, Минемөхәммәт, Йөзмөхәммәт, Нурмөхәммәт, Мулланур, Мәхмүдә, Габдулла, 1932елның 28 ноябрендә - Шафига (үлгән Шафиганың исеме җирдә ятмасын дип кушканнар), унынчысы 1939 елның 26 ноябрендә -Гөлнәфис. Ачлык-ялангачлык еллар булганлыктан, тиф авыруы килеп чыгу сәбәпле, балалары бер-бер артлы үлеп баралар. Болар арасыннын өчесе: Зәйтүнә, Шафига һәм Гөлнәфис исән кала.

Бәзәкә авылында ике колхоз булган: "Сталин" һәм "Ворошилов" исемендәге колхозлар. Бабабыз Миннәхмәт "Сталин" колхозында тимерче булып эшли, ә әбиебез Минеһәдия "Ворошилов" колхозында төрле эштә хезмәт куя, колхозда эшләүчеләргә ипи дә пешерә. Бабайның кулыннан килмәгән эше булмый: тимердән кечкенә кубыз да ясый, кызы Зәйтүнәгә уйнар өчен курчакларга кадәр тегеп бирә. Тора –бара туку станогы ясый, шул станокта киндердән тукып күлмәк- ыштаннар тегеп кияләр.

Илгә килгән афәт аларныңда гаиләсен читләтеп үтми, тормыш итү авырая. Әтиләре Миннәхмәт сугыш инвалиды, әниләре Минеһәдия каты гына авырый, Шафига белән Гөлнәфис эле кечкенә булалар. Шунлыктан тормыш йөген җигелеп тарту олы кызлары Зәйтүнә җилкәсенә төшә. Хәтта аңа мәктәптә белем алырга да насыйп булмый. Уку –язуга үзлегеннән өйрәнергә туры килә. Бөек Ватан сугышы башлангач Зәйтүнәне, Бондюг хәрби комиссариаты аша, хезмәт армиясенә алалар. Чиләбедә металлургия заводының тимер юл цехында вагоннардан тимер рудасы төяү -бушату эшендә 7 ел хезмәт итә. Хезмәттән кайткач озак еллар төрле эшләрдә эшли. Авылда Зәйтүнә апа бик хөрмәтле кешеләрдән саналды. Бик күп еллар авылда абыстай булып йөрде, бик күп кешеләрне дин белеменә өйрәтеп калдырды. 2007 елның 24 апрелендә бакыйлыкка күчте.

Миннәхмәт бабайның тугызынчы баласы (кызы), 1932 елның 28 ноябрендә Шафига дөньяга килә. Яшүсмер еллары авыр, Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Шулай булуына карамастан якынча 1949-1950 елларны Бәзәкә урта мәктәбен тәмамлый. Тормышлары авыр булу сәбәпле, чикләвекләр, гөлҗимешләр җыеп, эшкә урнашу теләге белән Казанга юл тота. Анда туганнары Бәнәт апага (бабайның туганы) туктала. Бәнәт апаның кечкенә генә тулай торак бүлмәсендә яшиләр. Алып килгән чикләвекләрен, гөлҗимешләрен сатып әзрәк ашап-эчеп торырлык акча юньләтә. Әренләп Казанның зонтиклар, сумкалар, чемоданнар ясый торган фабрикасында эшли башлый һәм икенче фатирга күчә. Фатир хуҗасының баласын карарга ярдәм итә. Казан медицина училищесына укырга керә. Эшләп укып аны тәмамлый. Кыямов Хәсән Хөсәен улы белән гаилә корып җибәрәләр.1958 елда Әлмәткә күченәләр. Анда 33 нче хастахәнәдә балалар бүлегендә эшли башлый. 1959 елда - кызлары Сәгыйдә , 1963 елда -Рәйхәнә, 1969 елда- уллары Ринат туа. 1964 елда йорт салалар һәм шунда яши башлыйлар. Шәһәргә эшкә йөрергә ерак булгач , Әлмәт “Татнефть” промыслово - геофизик конторасына сызымнар сызучы булып эшкә урнаша. Гомер буе шул эш урынында хезмәт куеп, Хезмәт Ветераны исеменә лаек булып, лаеклы ялга чыга. Гомер буе Әлмәт шәһәрендә гомер итеп 85 яшендә, 2017 елның 21 сентябрендә бакыйлыкка күчте һәм Бәзәкә зияратына җирләнде. Тормыш иптәше Хәсән, шул ук конторада трактор йөртүче булып эшли. Трактор колоннасы җитәкчесе дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1996 елның 21 апрелендә вафат булды, Әлмәт районы Елховой авылында җирләнде.

Олы кызлары Сәгыйдә Казан дәүләт медицина институтын тәмамлап, Чаллыда күз табибы булып эшләп, лаеклы ялга чыкты. Тормыш иптәше Равил белән игезәк балаларын үстереп, олы тормыш юлына чыгардылар. Бүгенгесе көнне Чаллы шәһәрендә бәхетле әби белән бабай булып гомер итәләр.

Икенче кызлары Рәйхәнә Казан инженер төзүчеләр институтын тәмамлап, “Газпром” системасында ПТО җитәкчесе булып эшләп лаеклы ялга чыкты. Тормыш иптәше белән бер кыз тәрбияләп үстереп , Әлмәт шәһәрендә бәхетле әби –бабай булып яшиләр.

Уллары Ринат Әлмәт политехник техникумын бетерде. Эшкуар булып эшләде. Тормыш иптәше белән бер кыз тәрбияләп үстерделәр. Кызганычка каршы 2021 елның 4 январенда бакыйлыкка күчте.

Миннәхмәт бабай белән Минеһәдия әбинең унынчы балалары Гөлнәфис (безнең әниебез) 1939 елның 6 ноябрендә дөньяга аваз сала. (Туу турында таныклыкны бабай 26 ноябрьдә генә яздырып ала, шунлыктан барлык документларда да туган көне 26 ноябрь итеп языла). Аның балачак еллары авыр , ач- ялангач сугыш елларына туры килә. Апасы Зәйтүнә белән

басуга крахмал алу өчен, эчерек  бәрәңге  җыярга йөриләр, ә көз көне алабута җыеп  икмәк пешерәләр.  Әтисе Миннәхмәт  әнигә дә агачтан кечкенә өстәлләр, урындыклар , уенчыклар , уку әсбапларын тутырып йөрү өчен фанерадан сумка ясап бирә.   Сугыштан сонгы авыр еллар булуына карамастан, әнинең белем алу теләге көчле була. Бәзәкә урта мәктәбен уңышлы гына тәмамлый.  Ул елларда Бәзәкә урта мәктәбе олы чишмә турындагы, тау башында урнашкан булган.  Мәктәп яны участогында колхозыбызга  яшелчәләр , җиләк-җимешләр үстерүдә  актив катнаша.  Бу бөтен эшне  мөгаллим, биология  укытучыбыз  Мәүлидә апа ??? җитәкләгән.

Алга таба укырга теләге көчле булу сәбәпле, әни  май заводында эшләү өчен, курсларга укырга керә. Күршедәге  Турай авылына йөреп укый.  Ләкин ни сәбәпледер  авылыбызда май заводы төзелмичә кала, шунлыктан “Кама” колхозына сыер савучы булып эшкә керә. Ул елларны фермада эшләве җиңелләрдән булмый.  Барлык хезмәт: сыер саву,  аларны ашату, асларын чистарту һ.б.  кул көче белән башкарыла.  Хезмәт сөючән һәм тырыш әниебезгә бу эшләр җиңел бирелә.

Әтиебез  Закиров  Минехан Кәрәми улы (туган елы 1941 ел 14 октябрь) 1962 елны  Красноярскийда  армия сафларында өч ел хезмәт итеп, туган йортына кайта. Аның кайтуына  әбиебез Шаймөхәммәт кызы Фатиманың (туган елы-1904 ел)  күзләре күрми торган  була.  Армиядән кайткач әтиебез, бәхет эзләп  читкә чыгып китми, әнисен тәрбияләп төп нигездә яшәп кала. Бер үзенә  тормыш  алып баруы бик  кыен була. Ә  апасы Маһирә  кияүгә чыгып төп йорттан киткән була.

Әтиебез Минехан  1962 елда  әниебез Гөлнәфискә өйләнү теләген белдереп тәкъдим ясый.  Шулай итеп матур гына тормыш корып җибәрәләр. Тырыш һәм хезмәт сөючән егеткә туган колхозыбызда эшләү өчен, белем алырга кирәк була. Һәм ул Алабуга СПТУ № 11 укырга керә һәм уңышлы тәмамлый.  Туган колхозыбызда эретеп –ябыштыручы булып хезмәт  куя.

1965 елны йорт салып керәләр, шул ук елны уллары Файзелхан 4 июньдә дөньяга килә. Ә Миннәхмәт бабабызга беренче оныгы белән озак куанырга насыйп булмый,  каты авырып китү сәбәпле, ул бакыйлыкка күчә.  Тормыш дәвам итә. Аларның ике балалары: уллары Дамир (1968 елгы) һәм кызлары Дамира (1975 елгы)  дөньяга килә.  Алар безне тырыш, хезмәт сөючән  итеп тәрбияләделәр.  Уллары Файзелхан  Бәзәкә урта мәктәбен уңышлы тәмамлап, бала чактагы хыялы-табиб булу теләген тормышка ашыру өчен, 1982 елны Казан дәүләт медицина институтының дәвалау факультетына укырга керде.  Аны уңышлы гына  1988 елны тәмамлап, Аксубай үзәк хастаханәсендә озак еллар хирургия бүлеген җитәкләде.  Бүгенгесе көндә Казанның 18 шәһәр поликлиникасында  табиб булып эшләвен дәвам итә.

Күп тапкырлар мактау грамоталары, рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. Тормыш иптәше Гөлнур белән кызлары Язилә, уллары Динарны тәрбияләп олы тормыш юлына чыгардылар. Ләкин мәрхәмәтсез үлем, тормыш иптәше Гөлнурны арабыздан алып китте. Бүгенгесе көндә өч оныгының кадерле бабасы булып тормыш итә.

Икенче уллары Дамир да эш сөючән, тырыш егет булып үсә. Уңышлы гына урта мәктәпне тәмамлый. Колхозда эшләү теләге белән авылда кала. Ләкин ходай тәгаләнең һәркем өчен билгеләнгән вакыты бар, олы тормыш юлына аяк баса алмыйча, 1985 елның 4 августында фаҗигале рәвештә вафат булды.

Кызлары Дамира (үзем) урта мәктәпне 1992 елда уңышлы гына тәмамлап, Алабуга медицина училищасына укырга кереп, шәфкать туташы һөнәрен үзләштерә. Аннары үзебезнең Менделеев районы үзәк хастахәнәсендә шәфкать туташы булып эшли. Ләкин тырыш, үз максатына ирешә торган кыз моның белән генә чикләнеп калмыйча, читтән торып Алабуга дәүләт педагогика университетының филология факультетын унышлы гына тәмамлый. Аннан соң туган авылыбыз Бәзәкә “Ләйсән” балалар бакчасында педагог -тәрбияче булып эшләвен дәвам итә.

Тормыш булгач гаиләгә шатлыгы да, кайгысы да килә. 2011 елны 28 ноябрендә безнең яраткан әтиебез Минехан Кәрәми улы арабыздан китте. Әниебез Гөлнәфис Миннәхмәт кызы бүгенгесе көндә кызы Дамира тәрбиясендә Аллага шөкер исән-сау гына яши. Быел хөрмәтле әниебез 85 яшен тутыра.

Шуның белән безнең кадерле бабабыз Мөфтиев Миннәхмәт Мөфтәхетдин улына багышланган язмабыз тәмам.

Бабаларың кем дип сорасагыз
Җир кешесе булган, билгеле.
Типсә тимер өзгән,
Сукса ташны изгән,
Кирәк икән борган Иделне.


Үткән тарихка сәяхәт кызыклы да, катлаулы да эш. Мин бу сәяхәт вакытында үз нәселемнең зур, эшкә кыю, куркусыз икәнлеген аңладым. Үткәннәрне барлап, киләчәк өчен зур байлык калдыруым белән чиксез горурланам.

Тарих шаһит диләр, тарих битләреннән,
Эзләсеннәр туганнарым үз эзләрен.

Бу эшемдә минем нәсел җебем,
Шул җеп белән тезелеп киткән
Ул минем газизләрем.

Бу Миннәхмәт  Мөфтәхетдин улына багышланган истәлекләр язмасын
кызы Гөлнәфис, оныклары Закирова Дамира, Закиров Файзелхан яздылар.
11 февраль 2024 ел.

***Бик зур рәхмәт зур хезмәт куеп бабасы, нәселләре турында шушы матур истәлекләрне язган өчен Гөлнәфис апага, аның кызы Дамирага!***


*Мөфтиев Минәхмәт Мөфтахетдин улы (Бондюг заводына пропускка төшкән фото)*



*Минәхмәт абзыйның хатыны Гатауллина Минеһәдия Гатаулла кызы*



*Бертуганннар Зәйтүнә, Гөлнәфис һәм Шәфига Мөфтиевалар*



*Зәйтүнә Мөфтиева*



*Шәфига Киямова (Мөфтиева)*



*Гөлнәфис Закирова (Мөфтиева)*



*Шәфига Киямова (Мөфтиева) гаиләсе белән Мәскәүдә*



*Гөлнәфис Минәхмәт кызы һәм Минехан Кәрәми улы Закировлар*



*Минәхмәт абзыйның кызлары гаиләләре белән сабантуйда*



*Гөлнәфис апа балалары Фәйзелхан һәм Дамира белән*



*Дамира Минехан кызы Закирова*



*Дамир Минехан улы Закиров, 1985 ел*




*Фәйзелхан Минехан улы Закиров гаиләсе белән. Мәскәү, 2012 ел*




*Фәйзелхан Минехан улы Закиров. 2021 ел*



*Шафига Минәхмәт кызы Киямова кызлары гаиләләре белән*



*Шафига Минәхмәт кызы Киямованың оныклары*



*Шафига Минәхмәт кызы Киямованың улы Ренат гаиләсе белән*